Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№35 (48)

6 декабрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

**30 НОЯБРЬДӘ КФУның АЛАБУГА ИНСТИТУТЫНДА VII ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СТУДЕНТЛАР КОНГРЕССЫ ВӘКИЛЛӘРЕ ЧЫГЫШ ЯСАДЫ**. Чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, КФУның ректоры Илшат Гафуров һәм Казан шәһәренең мэры Илсур Метшин да катнашты. Конгрессның эшчәнлеге берничә блокка (спорт, мәдәният, фәнни, волонтерлык эше һ.б.) бүленеп алып барылды.

• • • •

**3 ДЕКАБРЬ КӨННЕ** Илшат Гафуров җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Җыелышны ректор ике яңа хезмәткәр белән таныштырудан башлап җибәрде. Аларның берсе Яр Чаллы филиалының яңа директоры Мәхмүт Ганиев булса, икенчесе КФУның иҗтимагый-мәгълүмати үзәге җитәкчесе Юрий Алаев. Гадәттәгечә, икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин КФУдагы Үсеш программасының барышы белән таныштырды. Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе Сергей Ионенко кабул итү кампаниясенең әзерләнү эшләре турында мәгълүмат бирде. РФ Фән һәм мәгариф министрлыгы кабул иткән приказ буенча 2013 елның 1 сентябреннән югары уку йортына керү өчен дүрт имтихан тапшыру мәҗбүри булачак. Идарә итү һәм территориаль үсеш институты директоры Наилә Баһаветдинова Германиягә (Ю.Либих ис. Гиссен университеты, Гумбольдт университетының география институты, Берлинның Ирекле университеты) барып кайтуы турында сөйләде. Ректорат барышында университетның Тарих институтында фәнни-тикшерену лабораториясен булдырырга, Массакүләм коммуникация һәм социаль фәннәр институтының гамәли политология кафедрасы исемен гамәли политология һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр кафедрасына алыштырырга кирәк дигән нәтиҗәләр чыгарылды.

• • • •

Шул ук көнне Казан университетында Төркия Республикасының Казандагы Генераль Консулы **САБРИ ТУНЧ АНГЫЛЫ** кунак булды. Килүенең төп максаты – төрек уку йортлары һәм Казан университеты арасындагы хезмәттәшлекне ныгыту. Сабри Тунч Ангылы КФУ ректоры Илшат Гафуров белән шул өлкәгә кагылышлы мәсьәләләр буенча әңгәмә кордылар.

• • • •

**3 ДЕКАБРЬДӘ** Казан федераль университетында **SAMSUNG ELECTRONICS КОМПАНИЯСЕНЕҢ ИНТЕРАКТИВ БЕЛЕМ БИРҮ КЛАССЫНЫҢ АЧЫЛУ ТАНТАНАСЫ БУЛДЫ**. Чара КФУ ректоры Илшат Гафуров, Samsungның БДБ илләрендәге штаб-квартирасы президенты Джан Санг Хо, ТР фән һәм мәгариф министры Энгель Фәттахов, Samsungның БДБ илләрендәге штаб-квартирасы вице-президенты Джей Сул Ю, ТР мәгълүмат һәм элемтә министры урынбасары Юрий Багров катнашында узды.

• • • •

**3 ДЕКАБРЬ КӨННЕ** Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты **«ТАТНЕФТЬ» ААҖНЕҢ БАРЛЫК ГЕОЛОГИК БҮЛЕКЧӘЛӘРЕ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ ҺӘМ БЕЛГЕЧЛӘРЕНЕҢ КВАЛИФИКАЦИЯЛӘРЕН АРТТЫРУ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ КЕРЕШТЕ**. «Нефтьле геология өчен петрофизика һәм геофизика» исемле яңа программа буенча эшләү күздә тотыла. Декабрь аенда компаниянең 60 хезмәткәре монда белемен күтәрәчәк һәм әлеге масштаблы проектны 2013 елда да дәвам иттерергә уйлыйлар.

• • • •

**4 ДЕКАБРЬ КӨННЕ** Казан федераль университетында «Территорияләр үсеше: муниципаль җитәкчелектә стратегия менеджменты» **АЧЫК КУРСЛАР ОЕШТЫРЫЛДЫ**. Чара Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләренең квалификацияләрен күтәрү өчен үткәрелде. Республиканың барлык башкарма комитет җитәкчеләре КФУның Дәүләт һәм муниципаль җитәкчелек югары мәктәбе базасында дүрт тәүлек буе белемнәрен тирәнәйтәчәк. Алар өчен махсус лекция, тренинг һәм түгәрәк өстәлләр уздырыла.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Наилә Бадыкшанова фотолары

# Берьюлы ике диплом!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

5 декабрьдә Казан университетының Тарих музее янәдән талантлы студентларын җыйды. Чарада «Казан федераль университеты һәм «Париж-3, Яңа Сорбонна» университетларының «филологик белем бирү» юнәлеше буенча уртак икеләтә дипломнар һәм рәсми француз теле буенча Париж шәһәренең Сәүдә сәнәгать палатасы дипломнарын тапшыру булды.

Тантананы КФУ президенты Мәкъзүм Сәлахов ачып җибәрде. «Без әзерләгән белгечләргә чит илләрдә дә ихтыяҗ зур», – дип белдерде ул. Президиумда, шулай ук, ФСИ директоры Рәдиф Җамалетдинов, «Париж-3, Яңа Сорбонна» университеты профессоры Ле Сканфф Ивон, француз теле кафедрасы җитәкчесе Валентина Васильевалар бар иде.

«Париж-3, Яңа Сорбонна» университеты белән хезмәттәшлек элемтәләре 2006 елда ук ялганган булган. Бу килешү нигезендә студент чыгарылыш елында «партнер-университетта» бер семестр буе белем алырга тиеш. Моның нәтиҗәсе дә күз алдында: университетыбызны тәмамлаган дүрт студентка «Париж-3, Яңа Сорбонна» университеты дипломнары бирелде. Шул ук вакытта унике кешегә француз телендә туризм һәм кунакханә бизнесы буенча Париж шәһәре Сәүдә сәнәгать палатасының сертификатлары тапшырылды. Шунысы куанычлы: сертификат алучылар арасында бер унберенче сыйныф укучысы да бар. Димәк, киләчәк тә өметле! «Бу безнең өчен бәһаләп бетергесез тәҗрибә булды. Әйе, кайчагында кыенлыклар да килеп чыкты. Шуңа да карамастан, бу бик кызыклы процесс иде. Туган университетыбызның ярдәмен һәрвакыт тоеп тордык. Мондый мөмкинлек тудырганы өчен уку йортыбызга зур рәхмәтебезне белдерәбез», – дип кулына икеләтә диплом алган Кристина Тараканова тәэсирләре белән уртаклашты.

*▪ Өстәге рәсемдә «Париж 3, Яңа Сорбонна» университеты профессоры Ле Сканфф Ивон һәм КФУ президенты М.Сәлахов уртак диплом тапшыра.*
*▪ Икеләтә диплом бирү тантанасыннан соң.*

## • Фән дөньясында

# КФУда дөнья икътисады хәл ителә!

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

4-5 декабрь көннәрендә КФУның Территориаль үсеш һәм идарә итү институтында «Глобаль финанс кризис шартларында Европа һәм Россиядә икътисадый үсеш перспективалары» дип аталган Россия-Франция семинары узды. Әлеге чара елга ике мәртәбә үтә: берсе – илебездә, берсе – Франциядә.




Наилә Бадыкшанова фотолары

Семинар Франция делегациясе – икътисад фәннәре докторы Ранверсе Франсуа, Халыкара тикшерүләр үзәгенең икътисад аналитигы Жан-Пьер Паже, икътисад аналитигы Элен Питио-Клеман, Көнчыгыш телләрен һәм цивилизацияләрен өйрәнә торган милли институт профессоры Жюльен Веркёй һәм Халык хуҗалыгын фаразлау институты хезмәткәрләре катнашты.

КФУ ректоры Илшат Гафуров кунакларны уку йортыбызның эшчәнлеге, бездә тормышка ашырыла торган проектлар, уку йортының үсеш этаплары белән таныштырып, махсус презентация күрсәтте. Ул бүгенге КФУ эшчәнлегенең өстенлекле икътисади юнәлешләрен билгеләп үтте. Алар арасында уку йортына Россия галимнәрен тарту, «Фарма-2020» федераль программасында катнашу, студентларга банкка бәйле белгечлекләр буенча өстәмә белем бирү, КФУда квалификация үсеше үзәге, «Самсунг» тикшерүләр үзәге ачылуы, аларның эшчәнлеге һ.б бар.

Семинарда Россия фәннәр академиясенең Халык хуҗалыгын фаразлау институты профессоры, академик Виктор Ивантер «Россия икътисадының бүгенге халәте: анализ һәм кыска вакытка фаразлау» дип аталган доклад укыды. Ул Россия һәм Европаның финанс базарларын тасвирлады. Илебезгә дә Европада җәелгән финанс кризисы янавын искәртте ул. Анынча, Россиянең төп максаты – «Зур бәла» килеп җиткәнче ил ресурсларын мөмкин кадәр саклап калу. Моннан тыш, В.Ивантер хәзерге көндә Россиянең икътисади үсеш темпларының кимеп баруын да искәртте.

КФУның Территориаль үсеш һәм идарә итү институтында бу өлкәгә караган актуаль мәсьәләләр турында докладлар тыңлана, глобаль икътисади мәсьәләләрне чишүгә юнәлтелгән уртак карарлар, тәкъдимнәр карала. Сөйләшүләр 8 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк.

• Безнең канат

# Гыйлем дә, сәяхәт тә!

**Эльвина НӘҖИПОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

29-30 ноябрь көннәрендә КФУның Яшел Үзән филиалында Казан университеты профессорлары: А.Насыйров һәм В.Клоков истәлегенә багышланган «Физика-математика һәм гуманитар фәннәрнең актуаль проблемалары» дип исемләнгән халыкара фәнни-гамәли конференция үтте.

Конференция дүрт юнәлеш буенча әзерләнгән иде: «Табигый мохитләрне радиофизика юлы белән тикшерү һәм мәгълүмат системалары», «Механика һәм математиканың актуаль проблемалары», «Мәгарифтә заманча технологияләр», «Татар теле һәм әдәбияты: тарихы һәм бүгенгесе».

Без, татар филологиясе бүлегендә укучы студентлар, дүртенче юнәлеш буенча әзерләндек. Филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Йосыпов, филология фәннәре докторы, профессор Флера Сәйфулина, доцент Олег Хисамов, филология фәннәре кандидаты, доцент Энҗе Кадыйрова һәм филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров конференцияне оештыруда зур көч куйды.



Һәр юнәлеш үз эченә берничә секцияне алган иде. Татар филологиясенә багышланган юнәлеш тә өч бүленештә эшләде. Миңа татар әдәбияты секциясенә керергә насыйп булды. Секциянең җитәкчеләре: Флера Сәйфулина һәм Илһам Гомәров студентларның фәнни мәкаләләрен бик тә кызыклы, бүгенге көндә дә актуаль булуларын билгеләп үтте. Һәр чыгыштан соң барган дискуссия моның ачык мисалы. Студентлар үз эшенең нәрсәсе белән кызыклы, мөһим булуын тыңлаучы тамашачыга төгәл итеп, тиешенчә дәрәҗәдә җиткерә алды. Кызык булмаса, бу кадәр сорау туар идеме икән? Үзем Туфан Миңнуллинның «Саташу» әсәрендә әхлак мәсьәләсе турында чыгыш ясадым. Әхлаксызлык проблемасы бүгенге көндә бик актуаль, минемчә. Дүртенче курс студенты Альбина Йосыпованың Равил Фәйзуллин иҗатына багышланган чыгышы аеруча кызыклы иде. Магистратурада гыйлем алучы Булат Мәүлетов «М.Мәһдиев әсәрләренә бер караш» темасы буенча эшләнгән фәнни эше дә ошады. Башка секцияләрдә дә эш бездәге кебек гөрләп баргандыр дип уйлыйм.

Конференциянең тагын бер мөһим, дулкынландыргыч мизгеле – ул нәтиҗәләр ясау вакыты булды. Секция җитәкчеләре Флера апа белән Илһам абый конференциядә чыгыш ясаучы һәр студентка сертификатлар, безнең фәнни мәкаләләребездән тупланган җыентыкларны тапшырдылар. Урыннар да билгеләгәннәр икән. II курс студенты Зәринә Әхмәтвәлиеваның чыгышы иң яхшы дип табылды. Икенче урынга IV курс студенты Альбина Йосыпова белән Эльвина Нәҗипова, өченче урынга I курс студенты Айгөл Халитова белән магистр Булат Мәүлетов ия булды.

Конференциядән соң безне Свияжскига экскурсиягә алып бардылар. Борынгы, чал тарихлы утрау, безне үзенең матурлыгы, сере, тарихи истәлекләргә бай булуы белән әсир итте. Көн бик салкын булуына да карамастан, без экскурсиядән бик канәгать калдык! Әле торгызылып бетмәгән корылмалар булса да, аларның киләчәктә балкып торачагына шигебез юк!

Безгә онытылмас мизгелләр бүләк иткән оештыручыларга зур рәхмәтебезне җиткерәбез! Фән белән шөгыльләнүчеләргә алдагы көннәрендә дә уңышлар, фәнни үрләргә ирешүләрен теләп калабыз!

• Бездә кунак бар

# Идарә итеп кара!

**Рифат СӘЛАХ**

4 декабрь көнне КФУның Өзлексез белем бирү институтында Австрия галиме Пол Толчинский ачык лекция үткәрде. Дәрес алырга килгән һәркем аннан персонал белән идарә итүнең серләренә төшенә алды.



Пол әфәнде идарә итүнең күп серләренә төшенгән. Илебезгә килүенең төп сәбәбе – үз методикасын Британиядә генә түгел, бездә дә сынап карау. Хәер, университетыбызның кунакка чакыруын кире кагу да уңайсыз бит. «Шәхесләрнең тиз үзгәрүчәнлеген күздә тотып идарә итү һәм мәгарифтә, психотерапиядә, бизнеста оештыру технологияләре» дип исемләнгән лекциясен уку йортыбыз диварларында сөйләве студентларыбыз өчен дә сөенеч.

Персонал белән идарә итү мәсьәләсе илебез өчен яңалык. Танылган бизнес-тренер, зур төркемнәр һәм оешмалар белән җитәкчелек итү буенча белгеч Пол Толчинский бу өлкәгә аерым әһәмият бирә: «Дөнья бик тиз үзгәрә. Хәзерге коточкыч конкуренция шартларында оста идарә иткәндә генә оешманың киләчәге якты. Һәр эшче зур оешманы үз компаниясе итеп тойганда гына уңышка ирешеп була. Соңгы егерме ел эчендә мин инженерлык юнәлешендә эшләдем. Гади инженерлар белән беррәттән, урта һәм югары менеджмент вәкилләренә дә белем бирдем. Һәрвакыт ничек итеп зур компаниядә бердәм коллетив булдырып, эшнең нәтиҗәлеген арттырырга икән дип баш ваттым. Бөтен хезмәткәрләрне дә бер процесска куша торган берничә методология уйлап таптым».

Күпчелек оешмаларда галим «аралаштыру» ысулын кулланырга тәкъдим итә. Хезмәткәрләр гадәттә үтәгән вазифаларыннан башка юнәлешкә күчә. Толчинский сүзләренчә, болай итеп һәр хезмәткәр бер-берсеннән нәрсәдер өйрәнә: «Кеше ситуациядә иң яхшысы булу теләге, киләчәген күрүе һәм һәр гамәлгә беренче адым ясау теләге булганда гына уңышка ирешеп була. Тикшеренүләрем бу теориянең хаклыгын раслады. Хәзер бу ысулны сезнең белән дә тикшереп карыйсым килә», – ди Пол Толчинский.

Пол Толчинский сүзләрен үз тәҗрибәсеннән китергән мисаллар белән үреп барды. Дәрестән соң, галим студентларны бизнес өлкәсендә кызыксындырган сорауларга җавап бирде. Киләчәктә студентларыбызга бу теорияләрнең кирәк булуы бар бит! Бүгенге күпчелек зур оешмаларның җитәкчеләре дә безнең белән бер бинада укыган бит!

• Очрашу

# Җен-пәриләргә ышанасызмы?

**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Телефонның смс килүдән селкенеп куюына тәмам аңыма килдем: «Сәлам! 4 декабрь көнне сәгать бердә Нәбирә Гыйматдинова һәм Мансур Гыйләҗев белән очрашу була. Керәбезме?»



«Укыйсы килми бу китапны» дип, еракеарак этеп куйдым да, хыялларыма ирекле очыш бүләк итеп, китапханәнең зур тәрәзәләреннән кышкы урамга багам. Карлар ява. Тик биюләре генә әллә нинди тынычсыз кебек тоела. «Юк-бар турында уйланып, үтәр инде кеше гомере» дигән гыйбарәдән кинәт кенә аңыма киләм. Шундый кискен фикернең хуҗасын эзләп, як-ягыма борылам. Гаҗәп! Янымда кеше заты тапмагач, тоелган гынадыр дип, кабат китап сәхифәләренә мәгънәле сүзләр артыннан чумам. «Сәер сез, кешеләр. Гади генә хакыйкатьне дә шулкадәр авырлык белән кабул итәсез». Бу сүзләрне аңлап җиткермәстән, йөрәкнең ярсуын тынычландырырга теләпме, тизрәк тавыш килгән якка карашымны юнәлтәм. Ни күрим: янымa буйга кечкенә булган ак сакаллы бабай утырган икән.

*– Гафу итегез, Сезне искәрми калганмын.*

– Мине бөтен кеше дә күрә алмый шул. Китапны күңелләре белән укучылар гына минем барлыгыма ышана.

*– Кем соң Сез?*

– Мин – Китапханә хуҗасы.

*– Юк, юк, ышанмыйм. Йорт ияләре, мунча пәриләре турында ишеткәнем, укыганым бар, әмма Сезнең хакта берни дә.*

– Әгәр дә аларның барлыгына ышанасың икән, мине дә кире кага алмыйсың. Кеше үзе ышанган нәрсәләрне генә күрә белә. Ышанусыз безнең куллар богаулы, күзләр бәйләнгән. Әнә язучыларны кара: алар үзләренең каләмнәреннән төшкән һәр сүзгә, һәр каһарманга ышанганнар.

*– Ха-ха, сихергә, тылсымга ышану дияргә телисезме Сез?*

– Анысын һәрберебез үзе билгели. Иң мөһиме: хакыйкатькә ышану кирәк. Дөреслеккә.

Телефонның смс килүдән селкенеп куюына тәмам аңыма килдем: «Сәлам! 4 декабрь көнне сәгать 13:00дә Нәбирә Гыйматдинова һәм Мансур Гыйләҗев белән очрашу була. Керәбезме?» Бу чара әле генә булган серле әңгәмәнең дәвамы түгелме соң? Әйтерсең Китапханә хуҗасы нидер җиткерергә тели...

Очрашуга кергәндә, мин теге бабайның эзәрлекләвен көткән идем, әмма чара башлану белән, әллә ничек тынычланып, игътибар тулысы белән кунак булып килгән шәхесләргә күчте.

Укучыларны киң аудиториясен Нәбирә Гыйматдинованың иҗаты тылсымлы булуы белән җәлеп итә. Ә икенче кунагыбыз Мансур Гыйләҗев исә үзенең кабатланмас сәхнә әсәрләре белән мәгълүм. Шундый талантлы шәхесләр алдында бермәл югалып каласың кебек, тик җылына барган аралашуга тиз ияләшеп китәсең дә, кунаклардан ниндидер яңалык, гайре табигый сүз ишетәсе килә башлый.

Нәбирә Гыйматдинованың әсәрләрен әдәбият белемендә магик реализм юнәлешендә тикшерәләр. Чыннан да, гайре табигый көчләрнең кеше тормышында әһәмиятле роль уйнавын мавыктыргыч сюжетлар яссылыгында бирү – гадәти булмаган күренеш. Шул уңайдан татар филологиясе бүлегенең 5 курс студентлары Айгөл Батрханова һәм Ләйлә Фәхриева, язучының иҗатын анализлап, кызыклы күзәтү ясадылар.

Студентлар белән кунаклар арасында күренмәс киртә, сораулар бирелә башлагач, эреп юк булды. Чара тагын да җылынып китте. Язучыларыбызның әле берсенә, әле икенчесенә бер олау сораулар бирелә барды. Нәбирә ханымны күпчелек магик персонажлары турында сорасалар, Мансур әфәндегә татар драматургиясенең киләчәге хакында шактый гына уйланырга туры килде. Чарага ниндидер серле рух өстәп, аноним хатлар да килеп төшкәләде.

Үзенең бер җавабында Мансур Гыйләҗев хәзерге көн тамашачыларына, гомумән, әдәбият, сәнгать белән кызыксынучыларга үз бәяләмәсен биреп китте: «Мин җитди әсәр язып карадым («Бичура»), ләкин халык аны аңламады. 5 ел уйналганнан соң, ул сәхнәдән төшеп калды. Яздым «Казан егетләрен» – халыкта икенче реакция, халык яратты. 15 ел буе уйналды. «Тагын Казан егетләре»н иҗат иттем – шул ук хәл. Нәтиҗә: халыкка авыр, уйлый торган әсәрләр түгел, ә җиңел, көлеп кенә утыра торганнары кирәк».

Чара кызып килә дисәң дә була. Вакытның тыгызлыгы сизелсә дә, һаман нәрсәдер беләсе килү теләге кимеми. Кунаклар да, студентлар да берсен-берсе үз итеп, очрашу мизгелен тиз генә тәмамларга ашыкмый. Аннары соң күңелле ыгы-зыгы башланды: чәчәкләр, истәлеккә дип фотосурәткә төшү, рәхмәт сүзләре – болар барысы да җандагы канәгатьлек хисен югары күтәрә иде.

Шушы картинаны күзәтеп утырганда, янымда ниндидер затның барлыгын тойдым. Китапханә хуҗасы икән! Аның елмаюлы күзләре миңа сынап карыйлар иде. Ә минем караштa – ышаныч!

• Юбиляр

# Дөньяны кочып яши ул...

**Гөлчәчәк ХӨСНУЛЛИНА,**
Татар филологиясе бүлеге студенты

Университетыбызны тәмамлагач, аны беркайчан да ташламаган кешеләр сирәк. Күптән түгел 55 яшен билгеләп үткән Галимҗан Гыйльманов та шундыйлардан. Моннан берничә ел элек ул «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсен җитәкли иде. Узган атнада Галимҗан ага яңадан Казан университетына кайтты. Гомер бәйрәмен үткәрергә язучы нәкъ менә туган университетын сайлаган.

Аның шигырьләре дә үзе турында сөйли. Мин шундый, мин мондый дип кычкырып йөрмичә, әкрен генә кулына каләм алып, үзе белгәннәрен, күргәннәрен, кичерешләрен ак кәгазьгә төшерә ул. Ул – серле шәхес. Аның дөньясын белү өчен, озаклап сөйләшү дә кирәкми - бер утырып шигырь, хикәя, парча җыентыкларын ачып уку да җитә. Аларда – аның язмышы, үткәне, бүгенгесе. Кыскасы, бөтен барлыгы...

Йә инде, көттермә, кем соң ул, сүзең кем турында диярсез. Ярый, серемне ачыйм, булмаса. Сүзем танылган язучы, шагыйрь, прозаик Галимҗан Гыйльманов турында.

Ул – Башкортстанның Дүртөйле районы Әсән авылы егете. Биредәге табигать аны шагыйрь иткәндер, мөгаен. Шулай булмыйча, татарга Шәехзадә Бабичны биргән мәшһүр авыл бит ул.

Баксаң, укучы күңеленә мәңге яшь булып кереп калган Галимҗан абый Гыйльмановка да 55 тулган икән! «И, бу гомерләр!..» Залда утырган һәр тамашачы, экранда шагыйрьнең балачак, студент, яшьлек елларындагы фотолардан торган язманы күреп, үз эченнән генә шулай дип уйлагандыр. Әйе, бер экранга, бер шагыйрьнең үзенә карап сокланып утырды тамашачы.

Галимҗан абый үзе дә халыкның җылысын, яратуын тоядыр мөгаен. Сабыйларча самими елмаюы белән, сүз арасында шаян сүзләр әйтеп, укучыларына атап шигырьләрен укыды ул. Кичәнең җылы үтүе - тамашачылар арасында Галимҗан абыйның тормыш иптәше Гөлнур ханым белән бергә, әнисе – Нәзилә апаның булуыннан да иде булса кирәк. Шигырьләрен укыганда әнисеннән күзен алмады ул. Ана белән бала арасында гына була торган җылылык шулхәтле көчле иде ки, бу халәт шагыйрьгә үз-үзен ышанычлы тотарга мөмкинлек бирде.

Галимҗан Гыйльманов тыштан җитди булып күренсә дә, күңеле белән яшь, шаян, шук икән. Үзе укыган пародияләрне, төрле елларда язылган шаян шигырьләрен тыңлаганнар минем белән килешәдер. Шагыйрьнең таланты көчле, иҗаты зур икәнен аны тәбрикләргә килгән кунаклар исәбеннән дә чамалап була иде. Республикабызның премьер-министры Илдар Халиков



җылы сүзләрен һәм истәлекле бүләк – кул сәгате тапшырды. Министрлар Кабинетыннан килгән котлауларның, шагыйрьнең күпкырлы иҗатын хәтерләткән төрле төстәге чәчәк бәйләмнәренең очы-кырые юк. Роберт Миңнуллин, Фоат Галимуллин, Тәлгать Галиуллин, Вакыйф Нуриев, Фәрит Яхин каләмдәшләренә җылы сүзләрен җиткерде. ФСИның директоры Рәдиф Җамалетдинов исеменнән юбилярны татар филологиясе бүлеге җитәкчесе Флера Сәйфулина котлады, аның әдәбиятыбызга керткән өлешен югары бәяләде.

Кичәнең күңелле рухта үтүендә студентлар да сәбәпче булды. Алар шагыйрьнең иң матур әсәрләрен сайлап, алдан әзерләнгәннәр. Әйтергә кирәк, мөгаллимәләребез Ләйлә Минһаҗева һәм Гөлүсә Гәрәевалар әсәрләрне уңышлы сайлаганнар. Кыскасы, кичәдә бер артык җир дә, ким урын да табылмады. Шигырьләр, парчалар, истәлекләр, Галимҗан абыйның үзенең сүзләренә язылган матур җырлар да, бер-берсе белән үрелеп, югары зәвык белән эшләнгән мәрҗәннең асылташларын хәтерләтте. Җырчы Нурзадә, Ринат Шаһидуллин кебек мэтрлар белән беррәттән, татар филологиясе бүлегенең I курс студенты Алсу Габдуллинаның моңлы тавышы да Галимҗан абыйның иҗатын яңа яктан ачты.

Кичә ахырына җиткәндә: «Мин дә бер генә сүз әйтим әле», – дип, Нәзилә апа торып басты. Тамашачыларга карап, улын зурлап килгәннәре өчен олы рәхмәтләрен җиткерде ул. «Минем улым – йөрәк парәм бит ул», – дип, улының аркасыннан сөйгәндә һәр тамашачының күзләренә чык бөртекләре кунган иде.

«Мин инде тугызынчы дистәне ваклап киләм, Аллага шөкер, дүрт малай үстердем, дүртесе дә, шөкер, исән-сау, тәртипле булдылар, авызларына тәмәке дә капмадылар», – дип, уллары белән горурлану хисләрен яшермәде Нәзилә апа.

...Менә нинди икән ул Галимҗан Гыйльманов дигән «серле йомгак»: гади дә, акыллы да, уңган да, тырыш та, җитди дә...

• Безнекеләр

## Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА:
# «Шигырь - ул җан авазы»

**Динара ЗИННӘТОВА, Рифат СӘЛАХ**



Ләйсән элеккеге журфак – хәзергечә әйтсәк, массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институтының бишенче курсында укый. Татар шигърияткә сөючеләргә аның исеме күптәннән таныш. Республика матбугатында шигырьләре-хикәяләре еш басыла. Беренче курста «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсенә канатланып килеп кергән шагыйрә Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВАның быел беренче китабы дөнья күрде. Бер-ике атна элек ул Татарстан Язучылар берлегенә дә кабул ителгән. «Тере тынлык» исемле шигырьләр җыентыгы, гомумән, иҗат галәме турында үзе белән әңгәмә кордык.

**Ләйсән, син туганнан бирле иҗат дөньясында бугай. Китап чыгару теләге кайчан туды?**

– Китап чыгару турында һәр яшь шагыйрь-язучы хыялланадыр инде ул! «Казан утлары» журналы редакциясендә шагыйрь Равил Фәйзуллин: «Синең шигырьләрең китап чыгарырлык дәрәҗәдә, бастырырга кирәк», – дигәч, язганнарымны туплауга керештем.

**– Ни өчен китабыңа «Тере тынлык» исемен бирергә уйладың?**

– Мондый исем биредә җыелган шигырьләрнең эчтәлеген ачып бирә, минемчә. Күз алдыңа китер – әйтик, син тынлыкта утырасың. Башыңда шулкадәр күп уйлар, төрле фикерләр – син бу тынлыкта әллә ниләр уйлап, әллә ниләр ишетеп бетерергә мөмкинсең. Бу тынлык берничек тә үле була алмый. Гомумән, шигырь язган мизгелләрне дә тере тынлык белән тиңләргә мөмкин. Китапның азагында бу исемне аңлаткан юллар бар.

**– Гадәттә кызларның шигырьләре романтик төсмер йөртә, синең шигырьләрең турында исә бер дә алай әйтеп булмый. Ни өчен?**

– Бәлки, «романтик рухым» гына иң югары дәрәҗәгә җитмәгәндер. Иҗатымда романтик рух бар. Бүген күпләр романтиканы күктә очып йөрү, хыяллану, хисләнү дип күрә. Мин андый нәрсәне хуплап бетермим. Минемчә, кешенең хисе акылыннан аерылмаска тиеш. Бик хисләнеп алган вакытлар булса да, андый вакытта язылган шигырьләрне башкаларга күрсәтмәскә кирәк. Кеше синең хисләреңнән көләргә мөмкин. Ул очракта үзеңә мәңге төзәлмәс яра алачаксың.

**– Синеңчә, шигърият нәрсә ул: яр буенда үсеп утырган гөлчәчәкме, әллә инкыйлаблар кузгатырлык хәнҗәрме?**

– Шигърият, беренче чиратта, ул – җан авазы. Чәчәк тә, инкыйлаб та булырга мөмкин, иң мөһиме – ул ясалмасын. Бу очракта хәтта син «инкыйлаб ясыйм әле» дип башлаган әсәрең ахырдан чәчәк булып шытып чыгарга мөмкин.

**– Шигырьләреңдә син күбрәк дөньяның матур якларын яктыртасыңмы, әллә негатив күренешләргә игътибар бирәсеңме?**

– Тормышта мин күбрәк оптимизмны хуплыйм, ләкин пессимизмга бирелгән чаклар да була. Шигырьләрдә алтын урталык - реализм булырга тиеш дип саныйм. Чынбарлык турында уйланулар, бераз фәлсәфә, проблемалар каршында чарасызлык һәм көрәшнең әһәмияте шигырьләремдә күбрәк урын ала.

**– Сине ТР Язучылар берлегенә дә кабул иткәннәр, дигән сүз ишеттек.**

– Әле бу көннәрдә генә кабул иттеләр. Мин моңа бик шат. Язучылар берлегенә керү үз-үзеңә ышаныч һәм җаваплылык өсти. Берлеккә кабул ителгәнсең икән, хәзер синең иҗатың туктарга тиеш түгел! Моңа кадәр икеләнү хисләре булса да, хәзер артка чигенә алмыйсың.

**– Синең шигырьләреңне укыганда, еш кына аларда үзеңне танnetworkсың. Якын кешеләреңнең «Бу шигырең минем турындамы?» – дип сораганнары бармы?**

– Берничә кешенең алай әйткәне бар. Бәлки, бу шигырьнең актуаль булуын күрсәтә торгандыр. Әгәр дә күп кеше үзен күрә икән, димәк, бу – уңышлы шигырь.

**– Шигырьләрне ничек язасың?**

– Шигырь язу – ул чакырып китерә торган яки куып җибәрә торган халәт түгел. Ул үзеннән үзе язылырга тиеш. Рифмасы, ритмы яхшы туры килгән шигырьне теләсә кайсы вакытта язарга мөмкинмен, ләкин минем өчен андый әсәрнең бәясе юк. Чын шигырьне җаныңнан «сыгып» чыгарырга кирәк. Аның кайсыдыр җирендә ритмы, рифмасы килмәскә дә мөмкин. Сирәк язылсын, кыска булсын, әмма иң мөһиме – шигырьдә җаныңның бер тамчысы булырга тиеш.

• Хис илендә

# Кар кызы булып карадым

**Алсу НУРГАТИНА,**
татар журналистикасы бүлеге студенты

Урамда беренче кар төшү белән тирә-якка Яңа ел шаукымы тарала. Кибетләрдә чыршы уенчыклары, ясалма булса да, күңелгә яңа ел рухы өстәп торган чыршы ботаклары, ялтыравыклы кыңгыраулар. Бәйрәм рухы миңа да кагылдымы, ирексездән мәктәптә укыган чакта ничек итеп кар кызы булып йөргәнем исемә төшә. 11 сыйныфта Яңа ел бәйрәме иде...

Тиктормас, чамадан тыш шаян, берсеннән-берсе шук башлангыч сыйныфлар арасында үземне күз алдына да китермәгән идем. Хәтта кар кызы булырга ризалык биргәнем өчен үкенеп тә куйдым башта, ләкин ялгышканмын. Балалар арасында үзем дә кабат бер кайгысыз балачакка кайттым... Хәер, ул шуклыклар начар гадәт түгел, ә уңай сыйфатларның берсе икән...

Яңа ел шаукымында укытучы апабыз сыйныфтан кар кызы белән Кыш бабай сайларга кушкач, арабыздан беребез: «Нигә соң алар? Кыш бабайга барыбер ышанмыйлар бит», – дип әйтеп ташлады. Башкалар да аңа кушылды. «Кыш бабай белән Кар кызы булырга тиеш. Алар Яңа ел символлары», – диде укытучыбыз. Бәхәсебез шулай чәлпәрәмә килде...

Йокыдан гадәттәгедән иртәрәк уяндым. Башлангыч сыйныфларның «Яңа ел»ы сәгать сигездә үк башлана бит. Кар кызы киемнәрен кигәч, дустым Кыш бабай (анысы сыйныфташым Равил) белән бәйрәм үтәчәк бинага юнәлдек. Зур капчык күтәргән Кыш бабай белән Кар кызы булып, матурлап бизәлгән бәйрәм залына кердек. Исәнләштек, Яңа ел белән тәбрикләдек. Шуннан башланды инде күңелле уеннар, җырлар... Безне уратып алалар да, әле берәр көй сузалар, әле биеп җибәрәләр. Күпме кабатлап, тырышып өйрәнгәннәр бит, балакайлар. Бу кадәрле самимилек күзләрне дә яшьләндерде хәтта. Уеннарда да калышмадылар, җиңүчеләргә Кыш бабай бүләген тапшыра килде.

Кыш бабайдан бүләкләр алган арада сакалын да тартып карадылар, бияләйләрен дә салдырдылар. Кече сыйныфтагы бер кыз минем янга килде дә:

– Сине беләм инде, Алсу апа. Ә теге абый кем ул, танып кына булмый, – ди. Чын кыш бабай ул, дигән булсам да, ышанмады.

Бәйрәмдә без чын йолдызлар идек. Фотога төшәргә теләүчеләр дә бихисап! Бүләк алырга килгән нәниләр ялт иттереп бүләкне тартып ала да кача. Әллә Кыш бабай куркыныч инде?! Сыйныф бүлмәләрендә кибет уенчыклары, кулдан эшләнгәннәре сирәк. Без үз кулларыбыз белән ясап бизи идек... «Хәзер уку да катлауланды», – ди укытучылар. Шулайдыр.

Бәйрәмдә тамаша кылып аяктан егыла язгач, безнең кулларга да бүләкләр китереп тоттырдылар. Барлык балаларга да бүләк өләшкән Кыш бабайга да бүләк алу икеләтә күңелле, минемчә. Без, балалардан аермалы буларак, әле һаман могҗизага ышанабыз!

• Әкәмәт

# Укытучы көндәлегеннән

**Гөлгенә ИДРИСОВА**
татар филологиясе бүлеге студенты

*(юмореска)*

Йә Ходам, кайсы акыллысы шундый матур төшне бүлеп шалтырата инде, ә?! Будильник икән... Будильник??? Әле йокларга яткан гына идем бит, торырга да вакытмы?..

Чулпан кичә соң кайтты шул: педсоветта иде. Дәресләрдән соң ата-аналар җыелышын үткәрделәр, ә аннан соң «Явыз Иван» педсоветта була дип сөендерде. Әлеге кушамат иясе, ягъни мәктәп директоры, коллективта гына түгел, бөтен мәктәп, бөтен дөнья директорлары арасында явызлык буенча беренчелеккә чыгар иде шәт! Аның күзенә башын күтәреп, туры караучы кеше юк, куркалар!.. Әнә бит җыелыштан да калтыранып, бер сүз дәшмичә, гаепле кеше кебек чыгып баралар. Димәк, зәһәр елан агуын җитәрлек чәчкән. Бер карасаң, директорның шундый таләпчән булуы кирәк тә! Юкка гына Ала Карга урта мәктәбе районда алдынгылар рәтендә тормый бит. Укытучыларны әле ничек кенә кулда тота белә ул! Йомарлап ала да, учына җәеп сала. Җитмәсә, кытыршы учында лезгинка да биетә!

Урамда ни кыш, ни көз түгел. Элеккеге аклы-каралы кинолардагы кебек тирә-як төссез, ямьсез... Барысы да каядыр ашыга, йөзләре уйчан, караңгы, әйтерсең алар да кичә аның белән бергә педсоветта утырган.

Чулпан юл буена «Явыз Иван»нан башлап, сәгать дигән каһәр суккан нәрсәне уйлап тапкан кешегә кадәр сүгеп барды. Сәгать дигәннән, вакыт күпме соң? Өлгерәм икән әле... Алайса, сигездә мәктәп ишеген эчтән бикләп куялар. Бер безнең мәктәптә генә бар андый кагыйдә. Өлгермәсәң, укытучы башың белән, сумкаңны күтәреп кайтып китәсең инде. Ояты ни тора!



Ишек янында ук, Чулпанны классындагы укучы кыз каршы алды:

– Сәммесез, апа! Апа, бирегез сумкагызны алып барам!

Кемгә генә охшап куштан булдың соң син, Сөләйманова! Ярый, өстеңә кычкырып торуга караганда, куштанланып йөрүләре хәерлерәк тә!

– Апа, авырмыйсыздыр бит?.. Үзгәреп киткәнсез.

Үзгәрерсең монда сезнең белән, авырырсың да, тәүбә әстәгъфирулла! Чәчемне тарарга да онытканмын, бизәнү турында сүз дә юк инде. Килгән ди берәү укытырга! Ярый әле, Сөләйманова бар! Көзгегә дә карамыйча балаларны куркытып йөргән булыр идем бит.

– Чулпан Илһамовна, дәрестән соң миңа керерсез әле, – директорның карлыккан шомлы тавышы, Чулпанны бик тиз күктән җиргә төшерде.

– Ә юк, кереп тормагыз, шунда гына аңлатам, – дип дәвам итте ул сүзен. – Кичә сезнең классыгыз, ягъни 6нчы А, Совет урамындагы 18нче йортта яшәүче Шәмсенур исемле әбигә тимурчылык итәргә тиешләр иде, шулай бит? Ник дәшмисез?

– Ә.. ә... әйе, б...бардылар алар, Сания Мансуровна. Бардык, д...д...диделәр.

– Мәмерәгән тавык кебек басып торма, ичмасам! Әйтерләр алар, әле булыштык та дигәннәрдер. Бүген миңа әбиең шалтыратып, ник балаларыңны җибәрмисең, карт кешене сангa сукмыйсың дип, канымны кашыкка тамызганчы җикеренде.

Җикерерсең сиңа, бар! Сиңа тавыш күтәреп шалтыраткан өчен, ул әбиеңә медаль бирер идем, билләһи! Бу укучылары да инде, һәммәсенең үз сәясәте. Хәзер мин аларны!..

– Апа, бардык без, бардык! Әби, ачыгыз ишекне, без тимурчылар дидек! Ачмады.

– Өйдә юк идеме әллә?

– Өендә иде, кайда булсын! Капка аркылы гына: нинди тимерчеләр? Миндә бернинди дә тимер юк! Кирәкми дә, китегез моннан, полиция чакырам алайса, – диде.

Булган инде бу! Карчыгын әйтер идем, әллә нинди тимерләрең бардыр әле!..

Дәресләр беткәч, Аллага шөкер итеп, кайтып китәм дигәндә генә, профком килеп чыкты:

– Акча җыярга кирәк, пенсиягә китүчеләрне зурлап озатабыз. Нәрсә күзләреңне шакмакландырып торасың? «Иван»ны озатабыз, кызганып торма инде!

Ә-ә-ә?! Бик рәхәтләнеп, бик теләп, биш куллап, биш меңе дә җәл түгел!!!

Бүген урамда бигрәк матур! Ябалак-ябалак кар ява, кыш үзенекен итә, күрәсең. Урамда узып баручы һәр кеше Чулпанга елмаеп китә кебек...

• Сәламәтлек

# «Коры сөякләр мәсьәләсе» яки ябыгу турында

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

Соңгы арада бөтен иптәш кызларыма ниндидер «ябыгу җене» кагылды диярсең. Кемгә карама – бөтенесе килограммнарының санын киметү ысулларын эзли. Һичьюгы: «Каравыл! Тазардым!», – дип чаң кага. Чынлап та таза кыз булса бер хәл. Күп очракта исә карап торышка төз гәүдәле кызлар да һаман ябыгу ягын карый. Анорексия, булимия турындагы куркыныч янаулар да куркытмый аларны. Объектив карaганда, бу проблема ни дәрәҗәдә җитди икән? Кызларның зифа буй-сын өчен көрәшләре, аларның тормышында чыннан да могҗизалар булдырырга мөмкинме?


Бүген идеаль авырлыкны исәпләүдә иң популяр алым – танылган француз табибы Поль Брок формуласы. Әлеге метод кешенең авырлыгын, буй озынлыгын, килбәт үзенчәлекләрен һәм яшен исәпкә ала. 40 яшькә кадәрге кешеләрнең идеаль авырлыгын исәпләр өчен буй озынлыгыннан (см) 110ны алырга кирәк. 40 яшьтән узган кешеләргә буй күрсәткеченнән 100не минусларга кирәк. Шуны да исәпкә алыгыз: астеник, яки юка сөякле гәүдәле кешеләргә нәтиҗәдән 10% алырга, ә гиперстеник, яки калын сөяклеләргә киресенчә, 10% кушарга кирәк.

Статистикага караганда, дөньяда көн саен йөз меңләп хатын-кыз диетага утыра, һәм аларның 15% өчен ябыгу үзенчәлекле бер бәйлелек төренә – анорексия чиренә әверелә икән. Табиблар анорексияне наркомания һәм алкоголизм кебек авырулар белән бер рәткә куя, чөнки анорексиклар гадәттә үз чиренең җитдилеген аңлап бетерми, дәваланырга теләми. Моннан тыш, әлеге авыру төренә рецидивлар да хас. Шул ук статистикага караганда, подиумнарда танылган модельләрнең 72% анорексия һәм булимия белән авырый. «Ябыгу чире»ннән үлүчеләр саны 20% тәшкил итә, күпчелек очракта моның сәбәбе – йөрәк эшчәнлеге бозылу. Анорексиклар арасында үз-үзенә кул салучылар да шактый. Гомумән, диетамы ул, бөтенләй ашамыйча тору яки катлаулы физик күнекмәләрме – ябыгу белән артык мавыгу сәламәтлеккә җитди зыян салырга мөмкин.

Ә егетләр бу хакта ни уйлый, аларга нинди кызлар күбрәк ошый икән? Бу сорауга җавап табар өчен, КФУ студентларына мөрәҗәгать итәргә булдым.



**Ренат Баһаветдинов, массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты, 5 курс:** Миңа ябыклар да, тазалар да ошамый, «алтын урталык»ны тоткан кызлар ошый.




**Александр Титов, юрфак, 3 курс:** Әлбәттә, миңа зифа буй-сынлы кызлар ошый, «коры сөякләр» ошамый. Гомумән, мин артык ябыгуга тискәре карыйм. Иң мөһиме – үзеңне формада тотарга кирәк.



**Ленар Әмирханов, КФУның ВМК факультеты чыгарылышы:** Эш артык килограммнарда түгел, иң мөһиме – пропорцияләр саклануы!



**Айдар Хәлирахманов, юрфак, 5 курс:** Тыштан караганда, әлбәттә, зифа гәүдәле кызлар күркәм, шулай да мин кешенең авырлыгын ошау-ошамауда әһәмиятле фактор дип санамыйм. Иң мөһиме – кеше белән аралашу рәхәт булсын. Кеше ачык йөзле, киң күңелле, кешелекле икән – аның эчке матурлыгы тышына бәреп чыга. Син аның тышкы кимчелекләрен күрми башлыйсың. Миңа очраган «модель кыяфәтле» кызлар еш кына интеллектуаль яктан үсеп җитмәгән, дорфа сөйләшүче, әдәпсез булып чыга. Гомумән, ямьсез кызлар юк – зәвык төрлелеге генә бар, дип саныйм.



**Роберт Мәннанов, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты, 5 курс:** Зифа гәүдәлеләр матуррак дип уйлыйм, тик кызларга шундый сүзем бар: ябыгыр өчен ризыктан баш тарту – бик зур хата! Ашамыйча торып ябыгырга кыен, аш казанына гына зыян салачаксың. Күбрәк хәрәкәтләнергә, спорт белән шөгыльләнергә һәм сәламәт яшәү рәвеше алып барырга кирәк.

Егетләрнең сүзләренә карап, шундый нәтиҗә ясыйм: беренче урында – сәламәтлек, икенчедә – күңел яктылыгы, аннан соң гына – фигура!

• Кети-мети

ИКЕ ИШӘК ЙӨГЕ

Патша үзенең вәзире белән ауга чыккан. Көн эссе булганлыктан, икесе дә киемнәрен салып хезмәтчегә күтәрткәннәр. Боларга юлда Хуҗа Насретдин очраган.

– Кара әле, Хуҗа әфәнде, хезмәтчебез нинди көчле! Ул җилкәсенә бер ишәк йөген күтәреп бара, – дигән вәзир Хуҗага.

Хуҗа исә:

– Юк, вәзир әфәнде, артыграк. Хезмәтчегез ике ишәк йөген күтәргән, – дигән.

***

МИНЕ ТЫҢЛАМАС УЛ

Хуҗа шәһәр башлыгы белән ачулы булган икән. Көннәрдән бер көнне шәһәр башлыгы үлеп киткәч, Хуҗага әйткәннәр:

– Йә әфәнде, безгә килеп мәрхүмгә җеназа укысана!

Хуҗа риза булмаган:

– Юк инде, сез башка бер кешедән укытыгыз, мәрхүм миңа дошман иде, мине тыңламас ул, – дигән.

***

КЕМ КАНӘГАТЬ?

Берзаман Хуҗа Насретдин: «Кем дә кем байлыгына канәгать икәнлеген миңа килеп игълан итсә, шуңа ишәгемне бүләк итәм", – дигән.

Бу хәбәрне шәһәр башлыгына җиткерәләр. Ул Хуҗа янына килә дә:

– Якын-тирәдә миннән бай, байлыгына канәгать кеше юк. Шулай булгач, ишәк минеке, – ди.

– Гафу ит, – дип җавап бирә Хуҗа Насретдин. – Байлыгыңа тулысынча разый булсаң, кеше ишәген алырга килмәс иден!

***

БОЗАУ ВАКЫТТА УК

Беркөнне хан:

– Минем янга Хуҗа Насретдинны җибәрегез. Аның белән атка менеп бераз ярышып алырбыз, – дигән. Хуҗага бу хәбәрне ирештергәннәр.

Хуҗаның бер карт үгезе бар икән. Шуны иярләп өстенә атланган да, хан чакырган җиргә киткән. Хуҗаның үгез белән килүен күреп, кешеләр көлешә башлаган. Хан, Хуҗага карап:

– Әй, Хуҗа, ни өчен син үгезгә атландың? - дип сораган.

Хуҗа:

– Бу үгезнең бозау вакытта бик кызу чапканын күргәнем бар иде, аны ат та куып җитә алмый торган иде!

• Шигъри башваткыч

## Сабактуй

**Ринат НУРУЛЛИН**

*Бәйрәм булмый*
*бүләксез,*
*Бүләк булмый теләксез.*
*Бүләгем дә, теләгем дә*
*Артып калмас кирәксез.*

*Җитмәсә дә сабантуй,*
*Үткәрербез сабактуй:*
*«БҮЛӘК + ТЕЛӘК =*
*БӘЙРӘМ», – диеп*
*Дәфтәреңә язып куй.*

*Математик бәйрәмдә*
*Хәрефләрне әгәр дә*
*Цифрларга алыштырсаң,*
*Эшең китмәс әрәмгә.*

***(Башваткычның алты чишелеше бар.)***

! Узган санда чыккан башваткычның җавабы: 724 + 724 = 1448. Дөрес җавапны почтабызга җибәргән Нурсөя МИНЗИНА «Альпинист үрмәкүчләр»гә лаек булды. Ә Алинә Ганиева иң беренче булып җибәрү сәбәпле, ШБ лигасында 38 балл туплап беренчелеккә чыкты. Икенче урында Илмир Вәлиев 36 балл. Лига турында тулырак мәгълүматны vk.com/darelfonyn төркемендә укый аласыз.

**Безнең е-майлга башваткыч җавапларын җибәрүегезне көтеп калабыз!**

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева, Д.Р.Зиннәтова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.